**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 елның «23» декабреннән № 372

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 ст. 3 п., Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында»гы Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарын үтәү йөзеннән һәм РФ Хөкүмәтенең «Җирләү буенча махсуслаштырылган хезмәткә кире кайтарылырга тиешле хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең, шулай ук җирләүгә социаль пособиенең иң чик күләмен индексацияләү сроклары турында» 2010 елның 12 октябрендәге 813 номерлы карары гамәлдә булуын 2016 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып тору сәбәпле, карар бирәм:

1. 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә, Яңа Чишмә муниципаль районында 2016 елның 1 гыйнварыннан җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 5277,28 сум итеп билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган

хезмәтләрнең бәясе турында» 2014 елның 17 декабрендәге 539 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру бүлегенә әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Ритуаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче барлык милек формасындагы предприятиеләргә һәм оешмаларга әлеге карар белән расланган тарифларга таянырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2015 елның «23» декабрендәге
372 номерлы карарына
1 нче кушымта

**2016 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районда жирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| № т/б | Хезмәтләр исемлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|---|
| **1** | 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| **2** | Ритуаль билгеләнештәге кирәкле предметлар бирү | 2840,23 |
| **3** | Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмнең җәсәден зиратка илтү, ритуаль билгеләнештәге әйберләр китерү) | 775,43 |
| **4** | Җирләү (каберне казу һәм күмү) | 1661,62 |
| | **Барлыгы:** | **5277,28** |

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2015 елның «23» декабрендәге
372 номерлы карарына
2 нче кушымта

**2016 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районда жирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| № т/б | Хезмәтләр исемлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1 | 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2 | Кәфенләү | 300,00 |
| 3 | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны китереп бирү | 2540,23 |
| 4 | Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмнең җәсәден зиратка илтү, ритуаль билгеләнештәге әйберләр китерү) | 775,43 |
| 5 | Җирләү (каберне казу һәм күмү) | 1661,62 |
| | **Барлыгы:** | **5277,28** |